**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 27 гыйнвар № 38

г. Казань

2017 елда Татарстан Республикасының авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча чаралар исемлеген раслау турында

Россия Федерациясенең 2013 – 2020 елларга «Мәгарифне үстерү» дәүләт программасы кысаларында авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү хакында «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына федераль бюджет турында» 2016 елның 19 декабрендәге 415-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән 2017 елда Татарстан Республикасының авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча чаралар исемлеген (алга таба – Чаралар исемлеге) расларга.

2. Чаралар исемлеге тормышка ашыру буенча вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\38.docx